ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында» 438-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары А.К. Хамаев, Ф.Ф. Баһаутдинов, И.Ф. Салихов тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында» 438-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 13 июле
№ 2068-VI ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
А.К. Хамаев, Ф.Ф. Бaһаутдинов,
И.Ф. Салихов
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

Татарстан Республикасы Экология кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1; 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 1; 2013, № 1; 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 4; 2016, № 1 – 2, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш), № 44 (I өлеш); 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 54 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 34 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 35 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның 1 өлешендәге кырык җиденче абзацында «һәм объектлары» сүзләреннән соң «, үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы объектлары, табигый экологик системалар» сүзләрен өстәргә;

2) 94 статьяның 3 өлешендә «җирләрне сугару һәм ашлау» сүзләрен «сугару һәм башка мелиоратив чараларны гамәлгә ашыру» сүзләренә алмаштырырга, «санитар законнар» сүзләрен «санитария-эпидемиология таләпләре» сүзләренә алмаштырырга;

3) 95 статьяның 3 өлешендә «Җирләрне агып төшүче сулар белән сугару һәм ашлау» сүзләрен «Сугару һәм башка мелиоратив чараларны гамәлгә ашыру өчен агып төшүче суларны куллану» сүзләренә алмаштырырга;

4) 96 статьяның 3 өлешендә «мелиоратив эшләр әйләнә-тирә мохитне саклау, су объектларын һәм аларның су җыю мәйданнарын яклау» сүзләрен «мелиоратив чаралар әйләнә-тирә мохитне, су объектларын һәм аларның су җыю мәйданнарын саклау» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон 2023 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма**

«Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проекты Татарстан Республикасы законнарын федераль законнарга туры китерү максатларында эшләнде.

2023 елның 1 сентябреннән үз көченә керүче «Җирләрне мелиорацияләү турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясе Су кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 19 декабрендәге 539-ФЗ номерлы Федераль закон белән Россия Федерациясе Су кодексына түбәндәгеләргә багышланган нигезләмәләрне төзәтү өлешендә үзгәрешләр кертелде:

җир асты су объектларын саклауга;

су хуҗалыгы системасын проектлаганда, төзегәндә, реконструкцияләгәндә, аны файдалануга керткәндә, аннан файдаланганда су объектларын саклауга;

эшләр башкарганда су объектларын саклауга.

Закон проекты белән федераль законнардагы бу үзгәрешләрне Татарстан Республикасы Экология кодексында чагылдыру тәкъдим ителә.

Моннан тыш, 2023 елның 1 сентябреннән үз көченә керүче (аерым нигезләмәләрдән тыш) «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 18 мартындагы 77-ФЗ номерлы Федераль закон белән «Махсус сакланылучы табигать территорияләре турында» 1995 елның 14 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закондагы «махсус сакланылучы табигать территориясе» термины төзәтелде.

Шуңа бәйле рәвештә, закон проекты белән әлеге термин кергән Татарстан Республикасы Экология кодексының төшенчәләр аппаратына үзгәреш кертү тәкъдим ителә.

**«Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалтуы танылырга, туктатып торылырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары исемлеге**

«Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасының башка законнарының үз көчләрен югалтуын тануны, аларны туктатып торуны, үзгәртүне яисә яңаларын кабул итүне таләп итми.

**«Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектына финанс-икътисадый нигезләү**

«Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнарны таләп итми.